| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июнь 2026 ел №57

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территория җирләренә кертү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Балтач районы прокурорының 2026 елның 28 апрелендәге 02-08-01-2026/Прдп151-26-20920011 номерлы протестын карап, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1. Балтач район Советының 2012 елның 26 январендагы 83 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге җирләрне җирле әһәмияттә булган махсус саклана торган территория җирләренә кертү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) махсус саклана торган табигать территорияләре, шул исәптән дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар:

- дәүләт табигый тыюлыклары, шул исәптән биосфера, дәүләт табигать заказникларының җирләре,
- табигать һәйкәлләре,
- милли парклар,
- табигать парклары,
- дендрология парклары,

ботаника бакчалары.».

1.2. Нигезләмәнең 4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

Башкарма комитет район милкендәге җир кишәрлекләрендә җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләре булдыра. Әгәр төзелә торган махсус саклана торган табигать территориясе район милкендәге җир кишәрлекләренең гомуми мәйданының биш проценттан артыгын биләсә, Башкарма комитет махсус саклана торган табигать территориясен булдыру турындагы карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерә.

1.3. 8 пунктны үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль район Башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин